**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об утверждении показателей, необходимых для мониторинга обеспечения комплексного социально-экономического развития Республики Татарстан»

В целях совершенствования деятельности по мониторингу обеспечения комплексного социально-экономического развития Республики Татарстан **постановляю**:

1. Внести в приложение к Указу Президента Республики Татарстан от 29 июля 2009 года № УП-393 «Об утверждении показателей, необходимых для мониторинга обеспечения комплексного социально-экономического развития Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 29 февраля 2012 года № УП-159, от 17 марта 2014 года № УП-279, от 14 мая 2016 года № УП-411 и от 7 апреля 2018 года № УП-297), следующие изменения:

а) пункт 3.1 изложить в следующей редакции:

«3.1. Количество отказов в трудоустройстве инвалидов из числа состоящих на учете в центрах занятости, единиц»;

б) пункт 3.2 изложить в следующей редакции:

«3.2. Темп снижения количества погибших по результатам несчастных случаев, связанных с производством, по сравнению с прошлым годом, процентов»;

в) пункты 4.2 и 7 признать утратившими силу;

г) сноску, помеченную символом «***», изложить в следующей редакции:

«*** Показатель применяется в отношении всех территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, за исключением Управления Федеральной службы исполнения наказаний по Республике Татарстан.».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Исполняющий обязанности**
**Президента Республики Татарстан** **А.В. Песошин**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
29 марта 2019 года
№ УП-189

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау өчен кирәкле күрсәткечләрне раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау буенча эшчәнлекне камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау өчен кирәкле күрсәткечләрне раслау турында» 2009 елның 29 июлендәге ПУ-393 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 29 февралендәге ПУ-159 номерлы, 2014 елның 17 мартындагы ПУ-279 номерлы, 2016 елның 14 маендагы ПУ-411 номерлы һәм 2018 елның 7 апрелендәге ПУ-297 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Эшкә урнаштыру үзәкләрендә исәптә торучылардан булган инвалидларны эшкә урнаштырудан баш тарту очраклары саны, берәмлек»;

б) 3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2 Производство белән бәйле фаҗигале хәлләр нәтиҗәсендә һәлак булучылар санының узган ел белән чагыштырганда кимү темпы, процент»;

в) 4.2 һәм 7 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

г) «***» символы белән билгеләнгән искәрмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*** Күрсәткеч, Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән кала, федераль башкарма хакимият органнарының барлык территориаль органнарына карата кулланыла.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын башкаручы** **А.В. Песошин**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 29 март
№ ПУ-189